# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ
# (IV чакырылыш)

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

2023 елның 11 сентябре №44 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Әбсәләм авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131 Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 14.03.2022 ел, № 58-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 02.04.2022 № 575 «Җир кишәрлекләре территорияләрен, шәһәр төзелеше планнары буенча документларны әзерләү, килештерү, раслау, гамәлдә булу вакытын озайту, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәт бирү, аларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү үзенчәлекләре турында» Карары, 28.07.2004 № 45-ТРЗ “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгының 07.08.2023 № 47 карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2023 елның 5 сентябрендәге карары проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 06.09.2023 ел карары проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, уңай тормыш эшчәнлеге шартлары өчен кеше хокукларын үтәү, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Теркәп бирелгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 14.08.2014 № 36 карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» Бердәм порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы –
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин